КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 октябрь г.Казань № 1247

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартын раслау турында» 2016 ел, 3 май, 276 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 февраль, 82 нче; 2017 ел, 4 август, 552 нче; 2020 ел, 11 февраль, 85 нче; 2021 ел, 8 июль, 551 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы тармак министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта татар текстында «(алга таба – Ведомствоара штаб),» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Рәисенең 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб,» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасының дәүләт өлешенә ия эре, икътисадый һәм социаль әһәмиятле (система барлыкка китерүче) оешмалар, предприятиеләр һәм бюджет барлыкка китерүче предприятиеләр исемлегенә керә торган эре, икътисадый һәм социаль әһәмиятле (система барлыкка китерүче) оешмаларның финанс-икътисадый торышына атналык мониторинг;

Татарстан Республикасында теркәлгән Россия икътисадының система барлыкка китерүче оешмаларының җитештерү куәтләренең фактагы дәрәҗәсе турында атналык мәгълүматлар мониторингы.»;

3.1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ел саен IV кварталда хуҗалык җәмгыятьләренең идарә һәм контроль органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләре вәкилләренә (алга таба – дәүләт мәнфәгатьләре вәкиле) директив формалаштыру өчен планлаштырыла торган елга салым салганга кадәр табышның һәм салым салына торган табышның фаразланган күрсәткечләрен карап тикшерү;»;

4.1 пунктның икенче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чакыру буенча (тавыш бирү хокукыннан башка) республика башкарма хакимият органнары вәкилләре, дәүләт мәнфәгатьләре вәкилләре, Оешмалар вәкилләре, шулай ук тиешле квалификациягә һәм карарлар кабул итү өчен кирәкле махсус белемнәргә ия белгечләр (экспертлар) катнаша ала.»;

4.7 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тәкъдим итү характерына ия, шул исәптән дәүләт оешмалары җитәкчеләре һәм Татарстан Республикасы милкендә 50 проценттан артык акцияләре (устав капиталларында өлешләре) булган хуҗалык җәмгыятьләренең директорлар советларындагы дәүләт мәнфәгатьләре вәкилләре өчен квалификация күтәрү курсларын узу өлешендә;»;

5.1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктта «квартал саен» сүзләрен һәм «, шулай ук Оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлеге өчен тармак компетенциясендәге дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм дәүләт хакимияте органнарының җаваплылыгын арттыру максаты белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6. Министрлык министр боерыгы белән беркетелгән тиешле бүлекчә йөзендә түбәндәгеләргә анализ үткәрә:

газ, электр, суга, хезмәт хакы һ.б. буенча җыелган бурычларга, шулай ук ОКВЭД нигезендә ведомство буйсынуына карап оешмалар буенча ачык башкару эшләре булуга;

дебитор бурычы структурасына (Министрлыкның баланс комиссиясе утырышына Оешманың төп дебиторларын чакыру ихтималы белән);

барлык дәрәҗәдәге бюджетларга бурыч биреп, бурычлы Оешманың кредитор бурычы структурасына;

бухгалтерлык хисабы нигезендә финанс тотрыклылыгы күрсәткечләренә;

төп финанс-икътисад күрсәткечләренә (өстәлгән кыйммәт, табыш, үзкыйммәт, сәнәгать җитештерүе индексы, товарлар, әзер продукция запаслары төяп җибәрелде, табыш яки зыян (салым салынганга кадәр), инвестицияләр күләме, уртача айлык

хезмәт хакы, котельныйлар саны, челтәрләрнең озынлыгы, йөртелгән пассажирлар, ташылган йөкләр күләме, дебитор һәм кредитор бурычлары һ.б.);

җитештерелә торган продукцияне, шул исәптән экспорт продукциясен сату базарларына;

Татарстан Республикасы бюджетына мәҗбүри түләүләр һәм җыемнар буенча бурыч күрсәткечләренә һ.б.

Оешмаларның финанс-икътисадый хәлен анализлаганда шулай ук аларның өзлексез эшләвен тәэмин итүнең төп факторларына, чималны, материалларны һәм компонентларны чимал белән тәэмин итүгә, җиһазларның иминлеген саклауга һәм тотрыклы эшләвенә, нәтиҗәле логистика төзүгә, гамәлдәге һәм яңа сату базарларын үстерүгә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә, инвестиция активлыгын стимуллаштыруга һәм кадрлар белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән федераль һәм республика чараларында Оешмаларның катнашуына игътибар итәргә кирәк.»;

6.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.7. Оешма тәкъдим иткән материалларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык, финанс тотрыклылыгын киметү сәбәпләрен күрсәтеп, Оешма эшчәнлеге турында бәяләмә, Оешманың финанс-хуҗалык хәлен яхшырту чаралары планы проектын (кирәк булганда) һәм Комиссия карары проектын булдыра һәм Комиссия әгъзаларына җибәрә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар һәм икътисадый эшчәнлек төрләре буенча табышны мониторинглау һәм анализлау турында» 2018 ел, 9 март, 141 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ел саен, агымдагы елның 20 ноябренә кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә һәм контроль органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләре вәкилләренә (алга таба – дәүләт мәнфәгатьләре вәкиле) директив булдыру өчен планлаштырыла торган елга табышның фаразланган күрсәткечләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә.»;

3 пунктның икенче абзацында «вәкилләренә» сүзе алдына «мәнфәгатьләре» сүзен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында табыш күләмнәренең кимүенә комплекслы анализ үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмәдә:

3.1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ел саен IV кварталда хуҗалык җәмгыятьләренең идарә һәм контроль органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләре вәкилләренә директив формалаштыру

өчен планлаштырыла торган елга табышның фаразланган күрсәткечләрен карап тикшерү.»;

4.1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.7 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чакыру буенча (тавыш бирү хокукыннан башка) республика башкарма хакимият органнары вәкилләре, дәүләт мәнфәгатьләре вәкилләре, Оешмалар вәкилләре, фәнни хезмәткәрләр, шулай ук тиешле квалификациягә һәм карарлар кабул итү өчен кирәкле махсус белемнәргә ия белгечләр (экспертлар) катнаша ала.»;

4.8 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин